КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Республиканское агентство по печати
и массовым коммуникациям
Декабристов ул., 2, г.Казань, 420066

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ
Республика матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр агентлыгы
Декабристлар ур., 2, Казан шәһәре, 420066

Тел.: (843)570-31-22, факс:(843)537-91-04, ra.tatmedia@tatar.ru, tatmedia.tatarstan.ru

ПРИКАЗ БОЕРЫК

24.05.2024 № 117-п

«Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты исеменнән гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкара торган дәүләт бюджет учреждениеләренә вакытлы матбугат басмаларында сайлауларны һәм референдумнарны яктыртуга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78[1] статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78[1] статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы, «Бюджет учреждениеләренә һәм автоном учреждениеләргә башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен билгели торган норматив хокукый актларга һәм муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 22 февралендәге 203 номерлы карары, «Татарстан Республикасы бюджетыннан дәүләт бюджет учреждениеләренә һәм автоном учреждениеләргә башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен билгеләүгә вәкаләтле башкарма хакимият органнары турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 28 февралендәге 178 номерлы карары нигезендә БОЕРЫК БИРӘМ:

1. «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты исеменнән гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкара торган дәүләт бюджет учреждениеләренә вакытлы матбугат басмаларында сайлауларны һәм

референдумнарны яктыртуга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78[1] статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләүнең кушымта итеп бирелә торган тәртибен расларга.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесенең беренче урынбасары Э.Ф. Әхмәтовага йөкләргә.

Җитәкче А.С. Сәлимгәрәев

«Татмедиа» республика
матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр
агентлыгының
2024 елның 24 маендагы
117-п номерлы боерыгы белән
расланды

«Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты исеменнән гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкара торган дәүләт бюджет учреждениеләренә вакытлы матбугат басмаларында сайлауларны һәм референдумнарны яктыртуга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^{1}$ статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Тәртип «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы (алга таба – Агентлык) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты исеменнән гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкара торган дәүләт бюджет учреждениеләренә (алга таба – Учреждение) вакытлы матбугат басмаларында сайлауларны һәм референдумнарны яктыртуга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгели.

Бюджет акчаларын төп бүлүче, Учреждениегә субсидияләр бирүне гамәлгә ашыручы булып Агентлык санала, аңа, бюджет акчаларын алучы буларак, Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә бюджет йөкләмәләре лимитлары бирелә.

2. Субсидияләр Агентлыкка, Татарстан Республикасы бюджет акчаларын алучы буларак, тиешле финанс елында (тиешле финанс елында һәм план чорына) бирелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

## II. Субсидияләр бирү шартлары һәм тәртибе

1. Субсидия алу өчен Учреждение Агентлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

бюджет чараларын бирү кирәклеген нигезләгән аңлатма, анда субсидия суммасын исәпләү, шул исәптән тиешле эшләрне башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) башлангыч смета, күрсәтелгән булырга тиеш;

түләүләрне алучы физик затларның саны (уртача еллык саны) һәм мондый түләүләрнең төрләре турында мәгълүмат (әгәр субсидия бирү максаты күрсәтелгән түләүләрне башкару булса);

субсидия бирү турында килешү төзү планлаштырыла торган айның беренче числосына (алга таба – Килешү) салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар һәм процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурыч булмау турында салым органы белешмәсе;

Килешү төзү планлаштырылган айдан алдагы айның беренче числосына Учреждениенең Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән) кире кайтару буенча срогы чыккан бурыч булмау турында баш мөхәррир һәм баш бухгалтер яисә башка вәкаләтле зат тарафыннан имзаланган белешмә.

2. Документлар бер эш көне эчендә теркәлә. Агентлык әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән документларны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә аларда булган белешмәләрнең тулылыгын һәм дөреслеген тикшерә һәм субсидия бирү турында яисә субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

3. Учреждение Килешү төзү планлаштырыла торган айның беренче числосына түбәндәгеләр таләпләргә туры килергә тиеш:

Учреждениенең салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы юк;

Учреждениенең субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы юк, моңа Учреждениене үзгәртеп оештыру яисә бетерү, һәлакәтләрне (гадәттән тыш хәл) булдырмау, һәлакәтләрдән (гадәттән тыш) килгән зыяннарны бетерү һәм торгызу эшләрен башкару чараларын гамәлгә ашыруга субсидия бирү, законлы көченә кергән суд актлары буенча бурычларны, шулай ук федераль законнарда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актларында билгеләнгән башка очракларда бирелгәннәре керми.

4. Учреждениегә субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 3 пункты нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яисә күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

Учреждение тапшырган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

5. Субсидия бирүдән баш тарткан очракта, Учреждение әлеге Тәртипнең 3 пунктында каралган документларны Агентлыкка кабат тапшырырга хокуклы.

6. Субсидия күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

7. Субсидия бирүнең нәтиҗәсе булып вакытлы матбугат басмасында сайлауларны (референдумны) яктыртучы кимендә бер хәбәри материал чыгу тора.

Субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү срогы - субсидия бирелгән елның 31 декабреннән дә соңга калмаска тиеш.

8. Субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән алып биш эш көне эчендә Агентлык һәм Учреждение Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы

билгеләгән үрнәк нигезендә Килешү төзиләр, анда түбәндәге нигезләмәләр булырга тиеш:

субсидия бирүнең максатлары;

субсидия бирү нәтиҗәсенең төгәл, үлчәнергә тиешле күрсәткече;

субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү чаралары планы;

субсидия күләме;

субсидияне күчерү сроклары (графигы);

хисап бирү сроклары һәм тәртибе;

Учреждение субсидия бирүнең Килешүдә билгеләнгән максатларын, шартларын һәм тәртибен үтәмәгән очракта, субсидия суммаларын кире кайтару тәртибе һәм сроклары;

Килешүгә үзгәрешләр кертү нигезләре һәм тәртибе, шул исәптән Агентлыкка субсидияләр бирүгә бюджет йөкләмәләренең элек җиткерелгән лимитлары кимегән очракта;

Агентлык карары буенча берьяклы тәртиптә Килешүне вакытыннан алда туктату өчен, шул исәптән түбәндәгеләргә бәйле рәвештә, нигезләр:

Учреждениене үзгәртеп оештыру (кушу рәвешендә үзгәртеп корудан тыш) яисә бетерү;

субсидия бирүнең әлеге Тәртиптә һәм (яисә) Килешүдә билгеләнгән максатларын һәм шартларын Учреждение тарафыннан бозу;

Учреждение тарафыннан Килешүне бер яклы тәртиптә өзүен тыю.

Кирәк булганда Агентлык һәм Учреждение Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән үрнәк нигезендә Килешүгә өстәмә килешү яисә Килешүне өзү турында өстәмә килешү төзиләр.

9. Агентлык субсидияне Килешү төзелгән көннән алып 10 эш көненнән дә соңга калмыйча Учреждениенең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счетына тулы күләмдә күчерә.

## III. Хисап бирүгә таләпләр

10. Учреждение Агентлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

ай саен, хисап аеннан соң килә торган айның 10 числосыннан да соңга калмыйча, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнар турында хисап;

ел саен, агымдагы финанс елның 20 гыйнварыннан да соңга калмыйча, субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап һәм хисап финанс елында субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү чаралары планын гамәлгә ашыру турында хисап.

11. Әлеге Тәртипнең 12 пунктында күрсәтелгән хисапларның рәвешләре Килешүдә билгеләнә.

12. Агентлык Килешүдә Учреждениенең өстәмә хисап бирү рәвешләрен һәм аларны тапшыру срокларын билгеләргә хокуклы.

## IV. Субсидия бирүнең максатларын, шартларын үтәүне тикшереп тору тәртибе һәм аларны үтәмәгән өчен җаваплылык

15. Хисап финанс елында файдаланылмаган субсидияләрнең калган акчалары (алга таба - субсидияләрнең калган акчалары) хисап елыннан соң килүче елның 30 гыйнварыннан да соңга калмыйча Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш, моңа файдаланылмаган субсидия акчаларының калган өлешләрен агымдагы финанс елында әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга ирешү өчен җибәрү ихтыяҗы булу турында Агентлык тарафыннан карар кабул итү очраклары керми.

Субсидиянең калган акчаларын Агымдагы финанс елында әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга ирешүгә җибәрү ихтыяҗы булган очракта, Учреждение хисап елыннан соң килүче елның 20 гыйнварыннан да соңга калмыйча Агентлыкка Учреждениенең агымдагы финанс елына субсидиянең файдаланылмаган калган акчалары тәэмин итү чыганагы булган үтәлмәгән йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук Учреждениенең күрсәтелгән йөкләмәләре булуны һәм аларның күләмен раслый торган документларны (документларның күчермәләрен) җибәрә (физик затларга түләүләр буенча йөкләмәләрдән тыш).

Агентлык Учреждениедән әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән мәгълүмат алган көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча агымдагы финанс елында файдаланылмаган субсидия акчаларының калган өлешләрен әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга ирешүгә җибәрүгә ихтыяҗ булу яисә булмавы турында карар кабул итә.

Агентлык агымдагы финанс елында файдаланылмаган субсидияләрнең калган өлешләрен әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга ирешүгә җибәрүгә ихтыяҗ булу турында карар кабул иткән очракта, Агентлык һәм Учреждение арасында мондый карар кабул ителгән көннән алып өч эш көне эчендә Килешүгә өстәмә килешү төзелә.

16. Агымдагы финанс елында Учреждениенең субсидия исәбенә финанс белән тәэмин ителгән элекке түләүләрне кире кайтаруыннан керемнәр булганда, Агентлык Учреждениенең аларны әлеге Тәртипнең 1 пунктында билгеләнгән максатларга ирешү өчен файдалануы турында карар кабул итә, әлеге карар Учреждениенең үзендә элек башкарылган түләүләрне кире кайтару исәбенә финанс белән тәэмин итәлә торган йөкләмәләре (физик затларга түләүләр буенча йөкләмәләрдән тыш) булуы турында мөрәҗәгате, шулай ук Учреждениенең күрсәтелгән йөкләмәләре булуны һәм аларның күләмен раслаучы документлар (документларның күчермәсе) нигезендә кабул ителә.

Агентлык Учреждениедән әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән мәгълүматны алган көннән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча Учреждениедә элек башкарылган түләүләрдән файдаланылмаган акчаларны агымдагы финанс елында әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга ирешүгә җибәрү ихтыяҗы булу яисә булмау турында карар кабул итә.

17. Агентлык һәм дәүләт финанс контроле органы субсидия бирү максатларының һәм шартларының үтәлешен мәҗбүри тикшерүне гамәлгә ашыра.

18. Агентлык һәм дәүләт финанс контроле органы үткәргән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча субсидия биргәндә билгеләнгән максатлар һәм шартлар үтәлмәве

ачыкланган очракта, Агентлыкның тиешле таләбен алган көннән алып 30 эш көне эчендә субсидия Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

Учреждение тарафыннан субсидияне кире кайтару сроклары бозылганда, әлеге пунктның беренче абзацында билгеләнгән срок тәмамланган көннән алып 30 көн эчендә Агентлык законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына субсидия акчаларын кайтару чараларын күрә.